СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.07.2026 г. Заинск № 57

**Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 06 июлендәге 298 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү комиссиясе турында Зәй муниципаль районы Советының 2018 елның 06 июлендәге 298 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан муниципаль хезмәткәрләргә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне, тикшерү материалларын үтәвен таныклаучы:

Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү турында;

муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәве турында;»;

«б» пунктчасының беренче абзацында «муниципаль норматив хокукый актта билгеләнгән» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасының икенче абзацында «Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 416 номерлы карары белән расланган» сүзләрен «Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга.

2. Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә 2 нче Кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) комиссия составыннан Шәйхиев Рәис Раиф улын чыгарырга.

3. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Советының законлылык, регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Совет рәисе** **Р.Г. Кәримов**